БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17 декабрь 2019 ел № 222

**Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Балтач муниципаль районы бюджетыннан җирлекләр бюджетларына субсидияләр бирү турында Килешүләр төзү тәртибе хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.3 статьясы, Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Балтач муниципаль районы бюджетыннан җирлекләр бюджетларына субсидияләр бирү турында Килешүләр төзү Тәртибен расларга (1 нче кушымта).

2. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Балтач муниципаль районы бюджетыннан җирлекләр бюджетларына субсидияләр бирү турында Килешү формасын расларга (2 нче кушымта).

3. Карар 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләре буенча үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының рәсми сайтында baltasi.tatarstan.ru урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында pravo.tatarstan.ru бастырырга.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин

Татарстан Республикасы
Балтач район Советының
2019 елның 17 декабрендәге
222 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Балтач муниципаль районы бюджетыннан җирлекләр бюджетларына субсидияләр бирү турында килешүләр төзү**
**ТӘРТИБЕ**

1. Әлеге тәртип җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Балтач муниципаль районы бюджетыннан җирлекләр бюджетларына субсидияләр бирү турында килешүләр (алга таба - Килешүләр) төзүгә бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала.

Килешүдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) субсидияләрнең максатчан билгеләнеше;

б) субсидияне күчерү һәм тоту шартлары;

в) субсидия бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;

г) субсидия күчерү графигы;

д) субсидияләрне бирү һәм тоту өчен билгеләнгән шартларның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

е) финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирү вакыты һәм тәртибе.

Килешү, үзгәрешләр кертүне һәм аны өзүне күздә тоткан килешүгә өстәмә килешүләр билгеләнгән формалар нигезендә төзелә.

Килешү проектын әзерләү Балтач район башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла, Балтач район башкарма комитеты тарафыннан Килешү проекты Балтач районы башкарма комитетына җибәрелә. Килешүгә Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе һәм җирлек җитәкчесе Балтач район башкарма комитеты кул куя.

Субсидия алу өчен Балтач муниципаль районы җирлеге башкарма комитеты Балтач район башкарма комитеты билгеләгән вакытта Балтач район башкарма комитетына түбәндәге документларны тапшыра:

- Балтач район башкарма комитеты тарафыннан расланган форма буенча субсидия бирүгә гариза .

2. Балтач муниципаль районы бюджетыннан җирлекләр бюджетларына субсидияләр әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә форма буенча килешүләр төзү шарты белән бирелә.

Җирлекләр бюджетларына субсидияләр Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең касса хезмәте күрсәтү өчен ачык булган территориаль органнары счетларына күчерелә

Әлеге бюджетара трансфертларны килешү төзелгән вакытка кадәр бирү җыелма бюджет язмасы һәм касса планы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Субсидияләр бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә муниципаль район бюджеты керемен ә күчерелергә тиеш.

Субсидияләр бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына файдаланылмаган субсидияләрнең калган өлеше, Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләре нигезендә, Балтач муниципаль район бюджеты керемендә кире кайтарылырга тиеш.

Максатчан файдалануны контрольдә тотуны законнар нигезендә Балтач район башкарма комитеты һәм Балтач муниципаль районының финанс бюджет палатасы гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы
Балтач район Советының
2019 елның 17 декабрендәге
222 номерлы карарына
2 нче кушымта

## _________ НЧЕ КИЛЕШҮ

җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Балтач муниципаль районы бюджетыннан _________________ җирлеге бюджетына субсидияләр бирү турында

Балтач ш. т. п. «___»___________

Нигезләмә нигезендә эш итүче, Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе исеменнән ________________________һәм ________________________________ нигезендә эш итүче, __________________________________ җирлеге башкарма комитеты
(җирлекнең исеме)
исеменнән _______________________________________________, алга таба бергә "Яклар" дип аталучы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан җирлекләр бюджетларына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашуга субсидияләр бирү Тәртибе нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр.

### 1. Килешү предметы

1.1. Әлеге Килешүнең предметы булып Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан____________________________________________________________
(җирлекнең исеме)
бюджетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашуга___________________________________________территориясендә,
(җирлекнең исеме)
___________________________(___________________________________) сум
(суммасы язмача)
күләмендә Балтач муниципаль районының бюджет акчалары хисабына субсидияләр (алга таба - Субсидия) бирү тора.

### 2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Балтач район башкарма комитеты бурычлы:
2.1.1. Әлеге килешү төзелгәннән соң биш эш көненнән дә артмаган вакыт эчендә Балтач муниципаль районы бюджетыннан җирлек бюджетына субсидия бирүне тәэмин итәргә;
2.1.2. Субсидияләрнең максатчан кулланылышын контрольдә тотарга;

2.1.3. Бюджет йөкләмәләре чикләрендә (лимитларында) җирлек бюджетына субсидияне билгеләнгән тәртиптә күчерергә.
2.2. Балтач район башкарма комитеты хокуклы:
2.2.1. Фактта башкарылган эш күләмнәрен (күрсәтелгән хезмәтләрне, китерелгән товарларны), әлеге Килешү кысаларында бүлеп бирелгән акчаларны дөрес (хокуклы) куллануны сайлап тикшерү үткәрүне гамәлгә ашырырга;
2.2.2. Җирлек Субсидия биргәндә билгеләнгән шартларны бозган очракта, Субсидияне кире кайтаруны таләп итәргә.
2.3. Җирлекнең башкарма комитеты түбәндәгеләрне эшләргә йөкләмә ала:
2.3.1. Субсидияләрне максатчан файдалануны тәэмин итәргә;
2.3.2. Эшләрне __________________________ башкаруны тәэмин итәргә;
(көне, ае, елы)
2.3.3. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашуга җирлек бюджетына бирелгән субсидияләрдән файдалану турында хисап тапшырырга;
2.3.4. Соратып алу буенча җирлек тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартларның, максатларның һәм тәртипләрнең үтәлешен контрольдә тоту өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны тапшырырга;
2.4. Җирлек башкарма комитеты хокуклы:
2.4.1. Әлеге килешүнең үтәлешенә бәйле рәвештә аңлатма алу өчен мөрәҗәгать итәргә;

## 3. Субсидия күчерүнең тәртибе һәм шартлары

3.1. Субсидия Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының _______ елга һәм 20____ - 20____ еллар план чорына бюджеты турында карарда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.
3.3. Субсидияләр әлеге Килешү төзелгәннән соң биш эш көне эчендә җирлек бюджетына күчерелә.

## 4. Субсидия бирү шартлары бозылганда һәм Субсидиянең файдаланылмый калган өлешен кире кайтару тәртибе

4.1. Субсидияне бирү шартлары бозылган очракта, аны кире кайтару түбәндәге тәртиптә башкарыла.
Бүлеп бирелгән бюджет акчаларын кире кайтару кирәклеге турында приказ басылып чыккан көннән алып биш эш көне эчендә җирлеккә тиешле язма хәбәрнамә җибәрелә. Авыл җирлеге, Министрлыкның язма хәбәрнамәсен алганнан соң биш эш көне эчендә, акчаны кире кайтарырга тиеш.
Күрсәтелгән акчаларны билгеләнгән вакытта ирекле кире кайтарудан баш тартканда, әлеге акчалар суд тәртибендә түләттерелә.
4.2. Хисаптан соң килүче елның 1 гыйнварына Субсидиянең файдаланылмый калган өлешен кире кайтару түбәндәге тәртиптә башкарыла.
Җирлек тарафыннан субсидиянең калган өлеше агымдагы финанс елының беренче ун эш көне дәвамында Балтач муниципаль районы бюджеты керемено кире кайтарыла.
Ихтыяҗы расланган субсидия акчалары агымдагы финанс елында Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә шул ук максатларга җирлек бюджетына кире кайтарылырга мөмкин.

**5. Субсидиянең максатчан кулланылуын контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе**

5.1. Субсидияләрнең максатчан кулланылышын Балтач район башкарма комитеты контрольдә тота.

**6. Килешүнең гамәлдә булу вакыты**

6.1. Әлеге Килешү яклар тарафыннан имзаланган вакыттан үз көченә керә һәм яклар тарафыннан әлеге килешү буенча йөкләмәләрне тулысынча үтәлгәнче гамәлдә була.

**7. Якларның җаваплылыгы**

7.1. Авыл җирлеге башкарма комитеты бүлеп бирелгән субсидияне максатчан файдалану буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

**8. Субсидиядән файдалану турында хисап бирү тәртибе**

8.1. Җирлек әлеге Килешүнең 2.3.3 пункты нигезендә хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр, шулай ук, проектны гамәлгә ашыру вакыты Килешү төзелгән елдан соң килүче елда тәгәлләнгән очракта, - проектны гамәлгә ашыру тәмамланганнан соң 1 айдан артмаган вакытта кәгазь һәм электрон чыганакларда хисаплар тапшыра.

**9. Йомгаклау нигезләмәләре**

9.1. Әлеге Килешүне үзгәртү яклар инициативасы буенча гамәлгә ашырыла һәм әлеге килешүгә, аның аерылгысыз өлеше булып торган, өстәмә килешү рәвешендә рәсмиләштерелә.

9.2. Әлеге Килешүдә каралмаган барлык әйбер буенча Яклар Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына таяна.

9.3. Әлеге Килешү бер үк юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә: берсе - Совет өчен, икенче - Җирлек өчен төзелгән.

**10. Юридик адреслар**

Балтач район башкарма комитеты:

______________________________________________

Җирлекнең башкарма комитеты:__________________________________________

**11. Якларның Имзалары**

| | |
|---|---|
| Башкарма комитет | Балтач район башкарма комитеты |
| _________________________ | ________________________________ |
| М. У.______________ | М. У. _____________ |
| (имза) | (имза) |
| ____________________ | __________________ |
| (дата) | (дата) |